**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

№ 2164

01.07. 2026 ел

**«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проекты кысаларында 2020 - 2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 февралендәге 300 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» РФ Хөкүмәтенең 2025 елның 12 июлендәге 1048 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проекты кысаларында 2020 - 2027 елларга Тукай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 февралендәге 300 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 24 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшь гаиләләр - социаль түләүләр алуга дәгъва кылучылар исемлеген төзегәндә, Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән әлеге Кагыйдәләрнең 25 пункты «а» - «в» пунктчаларында күрсәтелгән яшь гаиләләргә карамаучы яшь гаиләләр өчен аерым алынган муниципаль берәмлек буенча күрсәтелгән исемлеккә кертелә торган яшь гаиләләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артмаган күләмдә квота билгеләнергә мөмкин.».

1.2. 15 пунктка түбәндәге эчтәлектәге «з» пунктчасын өстәргә:

"з) махсус хәрби операциядә катнашкан иренең (хатынының) һәлак булуы турында таныклык күчермәсе (булган очракта)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов